

## САГЫНУ ҺӘМ САБАК

«ВТ» хәбәрчесе уйланулары

> 2



## БАТЫРЛЫК ҮРНӘГЕ

Казан Ратушасында Ватан Геройлары көнен билгеләп үттеләр


> 2



## БАШЫҢА ТӨШСӘ...

Хәсрәт кемнәрнедер берләштерә, ә кайберәүләр аерылу чигенә барып җитә

> 3



## ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 183 (28956) | Шимбә | 10 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


# ҖИДЕ КАТ УКЫП, БЕР ТҮЛИСЕ

## БЕЛГЕЧЛӘР ЯЛГАННАН САК БУЛЫРГА КИҢӘШ ИТӘ

**«Коммуналь түләү кәгазендә тагын бер юл барлыкка киләчәк!» «Торакны мәҗбүри иминиятләштергән өчен аена 1 мең сум акча ала башлаячаклар!» Соңгы көннәрдә социаль челтәрләр әнә шундый эчтәлектәге хәбәрләр белән тулды. Әлеге төр хезмәт өчен ялгыш бер түләсәң, ул гомерлек булачак, дип тә куркыталар. Түлисеме, юкмы? Бу сорауга җавап бар.**

Социаль челтәрләрдә таралган бу видеоязманы күрмичә калучылар сирәктер. Анда киләсе елның 1 гыйнварыннан торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә яңа юл барлыкка киләчәге турында хәбәр итәләр. Бу – торакны иминиятләштерү. Айлык түләү күләме дә билгеле. Аз да түгел, күп тә түгел – 1 мең сум. Исәп-хисап счетын тикшереп тормыйча, иминиятләштерү өчен бер тапкыр түләсәң, үзеннән-үзе әлеге төр хезмәткә ризалык биргәнсең булып саналачак, имеш. Алга таба ул ай саен килеп торачак икән. Ә менә бер түләгәннән соң, торакны иминиятләштерүдән баш тартырга теләүчеләргә судтан башка юл юк, бу – бик озакка сузыла торган эш, фатирсыз калуыгыз да бар, дип кисәтәләр. Курыкмас җиреңнән куркырсың!

– Хәзер интернет заманы бит, коммуналь хезмәтләр өчен дә Дәүләт хезмәтләре порталы аша гына түләргә гадәтләндек, – ди Кукмарада яшәүче Гөлнара Илалетдинова. – Дөресен генә әйткәндә, ут-газ өчен күпме исәпләгәннәрен карап та тормыйм. Күпме язсалар, шулкадәр түлим. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дөреслек эзләүнең файдасы юк. Яңа төр түләү турында ишеттек. Тик торакны иминиятләштерүдән баш тарткан очракта, түләү кәгазендәге ул юлны ничек төшереп калдырырга икәне аңлашылмый. Интернетта счет-фактураның гомуми суммасы гына күренә бит.

Социаль челтәрләрдә таралган хәбәрдә торакны иминиятләштерү белән кайсы оешма шөгыльләнәчәге дә аермачык язылган. Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, әлеге иминиятләштерү компаниясенең «кайнар линия»сенә шалтыраттык.

– Мондый хезмәт торакны иминиятләштерү дәүләт программасы кысасында күрсәтелә. Ул гамәлдәге кануннарга каршы килми һәм киләсе елның 1 гыйнварыннан илнең аерым төбәкләрендә тормышка ашырыла башлаячак дип көтелә. Бу очракта торак бер айга иминиятләштереләчәк. Киләсе айда яңадан акча түлисе була. Иминиятләштерү очракларына торакның диварларына зыян килү, коммуникация системасы, сантехник җиһазлар керә. Болар барысы да аерым килешүдә күрсәтеләчәк. Шунысы да бар: бу – ирекле хезмәт. Ягъни телисең икән – түлисең, теләмәсәң – юк, – дип аңлаттылар оешмада.

«Бу яңалык Татарстанга кагыламы? Иминиятләштерү өчен түләгән очракта килешүне кайдан аласы?» кебек сорауларга: «Бу хакта мәгълүмат юк», – дип кенә җавап бирделәр.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Башкаладагы икенче бер оешмада торакны иминиятләштерү буенча агент булып эшләүче Нәҗия Мөбарәкшина сүзләренә караганда, бүген торакны иминиятләштерү – гайре табигый хәл түгел.

– Хәзер халыкны үгетләп йөрисе юк. Үзләре торакны иминиятләштерүебезне сорап мөрәҗәгать итәләр. Бу – ирекле хезмәт. Өстәвенә күп кешенең фатиры ипотекага сатып алынган, ә мондый очракта торакны иминиятләштерү – мәҗбүри шарт. Берүк хезмәт өчен ике тапкыр түләмисең бит инде. Чынга ашмас нәрсә белән башны бутамасыннар! – ди белгеч.

Татарстан торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов та шул фикердә. Аның әйтүенчә, халыкны махсус котырталар.

– Беренчедән, әлеге яңалыкны кем-кайда хәбәр итүе турында бернинди рәсми мәгълүмат юк. Бу имеш-мимешне социаль челтәрләрдә генә тараталар. Ә аны кем уйлап табуы билгесез. Бу – ялган мәгълүмат. Махсус рәвештә халыкның ачуын чыгаралар. Димәк, бу кемгәдер кирәк. Коткыга бирелмәгез! Икенчедән, бүген коммуналь хезмәтләргә бәя арттыру мәсьәләсен күтәрү, гомумән дә, мантыйкка туры килми. Ник дигәндә, коммуналь хезмәтләргә бәяләр декабрьдә артты гына бит әле. Гыйнварда ил халкы болай да яңа тарифлар буенча исәпләнгән түләү кәгазьләре алачак. Башка төр бәяләр арту булмаячак, – ди Дмитрий Романов.

Башкарма директор сүзләренә караганда, счет-фактурага яңа төр хезмәт өчен түләү кертү мәсьәләсе алай җиңел генә хәл ителми. Интернеттагы төрле имеш-мимешләргә ышанып, аларны туганнарга-дусларга таратырга керешкәнче, әнә шуны истә тотарга киңәш итә белгеч.

– Аерым бер идарәче оешманың яки иминият компаниясенең коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазенә өстәмә юл кертергә бернинди хокукы юк. Бу – сафсата! Белгәнебезчә, Казан халкына ишегалларыннан карны чыгарган өчен яңа түләү кертергә тәкъдим иттеләр. Бу хакта алдан ук мәгълүмат җиткерделәр. Кар чыгарган өчен түләргәме-юкмы икәнен күпкатлы йортларда яшәүчеләр фәкать үзләре хәл итәчәк. Моның өчен иң беренче чиратта җыелыш үткәрәләр, фатир хуҗаларының фикерен белешәләр. Ә торакны иминиятләштерү – һәркемнең үз иркендә. Сезне беркем дә мәҗбүр итә алмый. Бигрәк тә бүгенге заманда игътибарлырак булсагыз иде!

Эльвира ВӘЛИЕВА

## Куркыныч газ

Өч ел эчендә Татарстанда газ җиһазларының төзек булмавы аркасында 113 янгын очрагы теркәлгән. Барлыгы 16 кеше һәлак булган. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе башлыгы урынбасары Максим Трущин әйтүенчә, 18 очрак газ шартлауга бәйле. Фаҗигаләр газ баллоннарыннан дөрес файдаланмау сәбәпле килеп чыккан.

Янгында һәлак булган 16 кешенең 3е – балалар. 36 кеше җәрәхәтләнгән (4е – балалар).

## *Беренче тапкыр*

Татарстанның ДРКБ Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә беренче тапкыр балага сөяк җелеге күчереп утыртуның тәүге этабы башкарылган. Яман шеш һәм кан авыруларыннан интегүчеләрне шундый ысул белән дәвалыйлар. Моның өчен балага иң элек төп күзәнәк күчереп утыртырга кирәк. Үзәктә шуңа ирешелгән дә инде.

«Татар-информ» хәбәренә караганда, яман шешле сабый хастаханәгә быел октябрь аенда эләккән. Гаять катлаулы бу эшләрне, Мәскәүнең Дмитрий Рогачев исемендәге үзәге табиблары белән берлектә, ДРКБ һәм КФУ белгечләре башкарган.

Сүз уңаеннан, 2023 елда Татарстан табиблары һәм урта медицина персоналы хезмәт хакына өстәмә 141,9 млн сум алачак. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин күрсәтмәсе Министрлар Кабинеты сайтында чыкты.

## КАМАЗ тизлеген арттыра

КАМАЗ гыйнвар – ноябрь айларында барлыгы 39,8 мең йөк машинасы җитештергән. Бу – узган елдагыга караганда 200гә күбрәк сан. Шул ук вакытта завод ноябрь аенда 3,8 мең машина комплекты (2021 елның шушы ук аендагыга караганда 350гә кимрәк) эшләп чыгарган. Моны тулы приводлы йөк машиналары җитештерүгә вакыт һәм көчнең күбрәк сарыф ителүе белән аңлаталар.

Шул ук вакытта КАМАЗның двигательләр заводы да, 2021 елдагы белән чагыштырганда, җитештерүне арттырган. Ноябрь аенда предприятие 4,5 мең двигатель эшләп чыгарган (узган елдагыдан 50гә күбрәк). Ә 11 айда 44,2 мең двигатель эшләп чыгарылган (узган елдагы күрсәткечтән 1 меңгә диярлек күбрәк).

## *Юньлегә илтми*

Россиядә наркотик куллану аркасында һәлак булган балалар һәм үсмерләр саны 2017 елдан бирле 2,5 тапкыр арткан. Россия Эчке эшләр министрлыгының наркотиклар әйләнешенә контроль буенча баш идарәсе җитәкчесе Иван Горбунов әйтүенчә, шушы чорда наркотиклар куллану сәбәпле исәптә торучы балигъ булмаганнар саны 40 процентка диярлек кимегән. Шуңа да карамастан, вазгыять катлаулы булып кала.

Белгеч аңлатып үткәнчә, үсмерләрнең наркотиклардан агулану, шул исәптән үлү очраклары арту аеруча борчу тудыра. Ул шулай ук 4 ел эчендә беренче тапкыр балаларның наркотикларга бәйле җинаять кылу очраклары артуын билгеләп үткән. Аның сүзләренә караганда, 2017 елдан бирле мондый җинаятьләр саны 56 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, быел гыйнвар аеннан июльгә кадәрге чорда илебездә 20,3 тонна наркотик һәм психотроп матдә законсыз әйләнештән алынган. Шул ук вакытта, әйтик, 2018 елның шушы ук чорындагыга караганда җинаятьләр саны ике тапкыр кимеп, 200 меңнән 105 меңгә калган. Ләкин хәзер мондый очраклар янә арткан.

**Көн кадагында**

# «Онытылган» сумнар

**Сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, халыкның күпчелеге коррупция очраклары белән хастаханә һәм сырхауханәдә, җиргә бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә, бакча һәм мәктәптә, милек килешүләре төзегәндә очраша. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көнендә узган республика форумында бу һәм башка бик күп көн кадагында торган мәсьәләләр күтәрелде.**

Татарстан Фәннәр академиясенең перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге директоры Марат Сафиуллин билгеләп узганча, шулай да алда санап узылган тармаклар арасында сәламәтлек саклау һәм мәгариф – ришвәт алу буенча иң еш телгә алына торганнары.

– Болар – чыннан да лидер. Ни өчен шулай килеп чыга? Әлеге тармакларның җәмгыятькә кыйммәте зур булса да, хезмәткәрләренең хезмәт хаклары аз. Һәм граждannar җинаять эшләргә мәҗбүр була, – диде ул.

Аның сүзләренчә, бу хәл Татарстан, Россия өчен генә хас түгел, ә бөтен дөньяда шулай. Республикадагы вазгыятьне контрольдә тотар өчен халык арасында әледән-әле социологик сораштырулар уздырылуына да басым ясады ул.

Татарстан Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы Марс Бәдретдинов фикеренчә, бу мәсьәләдә түрәләр үзләреннән башларга тиеш. Чөнки коррупция хакимияткә булган хөрмәтне һәм аның абруен киметә.



pixabay.com


– Түрәгә халык дошманы итеп карыйлар. Әгәр ышаныч юк икән, безнең эшебезнең файдасы нидә соң? – ди ул.

Һәм мисалга бер депутатның керемнәр турындагы декларациядә миллиард сум акчасын күрсәтергә «онытып» калдыруын китерде.

– Монда миллион турында сүз бармый, ә миллиард! Әлеге депутат табышны шәхси бизнесыннан алганлыгын әйтте. «Әгәр хезмәткәр минем менә шундый, ә үзенең менә шундый акча алуын белсә...» – дип акланмакчы булды намуссыз депутат, – диде Марс Бәдретдинов.

Ахыры 2 нче биттә >

**Сүзгә-сүз**



**Владимир ПУТИН, Россия Президенты:**

Көнбатыш Украинадан оятсызларча файдаланды, үзенә кирәген суырды, Донбасста геноцид һәм террорга күз йомып, илне колониягә әйләндерде. Хәзер Украина халкын, ерткычларча, Россиягә каршы көрәшү коралы буларак куллана.

**(«Российская газета»дан)**

## РОССИЯДӘ – ЯҢА ЕЛ КАРШЫЛАУ

**«АльфаСтрахование» хезмәте Россия халкыннан Яңа елны ничек каршы алырга җыенулары турында сорашкан.**

- **41%** >> гаилә белән бәйрәм итә
- **26%** >> дуслар белән бәйрәм итә
- **16%** >> Россия буенча сәяхәткә җыена
- **9,3%** >> чит илгә очачак


## Сөенечле хәбәр!

**2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!**

**П2435** җомга саны — **Ташламалы бәя** **444 сум 54 тиен** — гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

**П2409** атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** **980 сум 10 тиен** — гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+